ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, 5, с.Бишня,
Зеленодольский район, 422528

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИШНЭ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Центральная ур., 5, Бишнэ ав,
Зеленодольск районы., 422528

# БОЕРЫК

2024 елның 05 феврале №1

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында»гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында»гы 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы карары нигезендә Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР ИТӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 2023 елнын 31 гыйнварындагы 11 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru («Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат

стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

**Бишнә авыл җирлеге башлыгы:** **И.М.Фатхуллин**

Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 05 феврале №1 карарына 1 нче кушымта

ТР Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә 2024 елнын 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4561,35 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка ташу | 1299,37 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2509,48 |
| **Барлыгы** | **8370,20** |

Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 05 феврале

ТР Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә 2024 елнын 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне төрү | 805,88 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 755,48 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка ташу | 1 299,37 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 2 509,47 |
| **Барлыгы** | **8 370,20** |